# КАРАР

**2022 елның 22 октябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Березняк авылыны урам-юл челтәренә су агызу торбалары урнаштыру (сатып алу, кайтару, урнаштыру, шартнамә буенча эшләргә түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Березняк авылында кышын һәм җәен юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт хакы түләү);
- Березняк авылы зиратында агачларын кисү (эшләргә шартнамә буенча түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- -янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларны комплектлау җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Березняк авылы клубына җиһазлар һәм спорт инвентарьлары сатып алу;
- Березняк авылы мәдәният йортына сәхнә киеме тегү, урнаштыру (материал һәм фурнитура сатып алу, шартнамә буенча эш өчен түләү) проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 274 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 139.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 137 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

2. Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Березняк авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга. «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Березняк авылыны урам-юл челтәренә су агызу торбалары урнаштыру (сатып алу, кайтару, урнаштыру, шартнамә буенча эшләргә түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Березняк авылында кышын һәм җәен юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт хакы түләү);

- Березняк авылы зиратында агачларын кисү (эшләргә шартнамә буенча түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- -янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларны комплектлау җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Березняк авылы клубына җиһазлар һәм спорт инвентарьлары сатып алу;

- Березняк авылы мәдәният йортына сәхнә киеме тегү, урнаштыру (материал һәм фурнитура сатып алу, шартнамә буенча эш өчен түләү) проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль

районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Шәрипов